**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләттәшләр эшләре буенча координация советы составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләттәшләр эшләре буенча координация советы төзү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-703 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 3 ноябрендәге ПУ-717 номерлы, 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1083 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-27 номерлы, 2016 елның 7 декабрендәге ПУ-1085 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2018 елның 2 февралендәге ПУ-132 номерлы, 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге ПУ-88 номерлы, 2020 елның 31 гыйнварындагы ПУ-50 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге ПУ-70 номерлы, 2022 елның 1 мартындагы ПУ-175 номерлы, 2022 елның 11 августындагы ПУ-544 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 3 апрелендәге 196 номерлы һәм 2024 елның 20 гыйнварындагы 42 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләттәшләр эшләре буенча координация советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан А.В. Хохоринны, К.Г. Яковлевны чыгарырга;

б) Совет составына Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улын – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын кертергә (килешү буенча);

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.А. Ратникованың – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты каршындагы Эксперт советы рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Д.Ә. Садыйкованың – «Яшьләр дипломатиясе һәм креатив коммуникацияләр академиясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

Д.Ф. Шакировның – «Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисенең беренче урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма

комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 07 февраль
№ 101